**МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

02.03.2016 № 21-53-10

Казан ш.

**Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын түләтү тәртибе турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.2 статьясындагы 4 пункты, "Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында" 8 май, 2010 ел, № 83-ФЗ Федераль законның 30 статьясындагы 19 өлеше, "Автоном учреждениеләр турында" 3 ноябрь, 2006 ел, № 174-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 3.17 өлеше, "Дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләренә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелә торган субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын тиешле бюджетка түләтү турында" 28.07.2010 ел, № 82н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 20.1.2 статьясындагы 4 пункты нигезендә, боерык бирәм:

1. Лицевой счетлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын түләтү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

"Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын түләтү тәртибе турында" 29.10.2010 ел, № 21-53-77 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын;

"Татарстан Республикасы бюджет учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын түләтү тәртибе турында" 29 октябрь, 2010 ел, № 21-53-77 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында" 01.12.2011 ел, № 21-53-78 Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы боерыгын.

3. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына бу боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә җибәрергә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы финанс министрының беренче урынбасары – Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаменты директоры М.Д.Фәйзрахмановка йөкләргә.

**Министр** **Р.Р.Гайзатуллин**

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 02.03.2016 ел, № 21-53-10 боерыгы белән расланды

**Лицевой счетлары Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Татарстан Республикасы бюджет һәм автоном учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын түләтү тәртибе**

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.2 статьясындагы 4 пункты, "Дәүләт (муниципаль) учреждениеләрнең хокукый хәлен камилләштерүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым законнар актларына үзгәрешләр кертү турында" 8 май, 2010 ел, № 83-ФЗ Федераль законның 30 статьясындагы 19 өлеше, "Автоном учреждениеләр турында" 3 ноябрь, 2006 ел, № 174-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 3.17 өлеше, Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 20.1.2 статьясындагы 4 пункты нигезендә эшләнеп, Татарстан Республикасы бюджетына тиешле финанс елына бюджет турында Татарстан Республикасы законы нигезендә элегрәк бирелгән субсидияләрнең агымдагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмый калган калдыкларын Татарстан Республикасы бюджетына түләтү тәртибен билгели:

лицевой счетлары Татарстан Респубикасы Финанс министрлыгында ачылган Татарстан Республикасы дәүләт бюджет һәм автоном учреждениеләренә, дәүләт унитар предприятиеләренә (алга таба – учреждение, предприятие) Татарстан Республикасы дәүләт милкенең капиталь төзелеш объектларына капитал салуларны хәл итүгә яки Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез милек объектларын сатып алуга (алга таба – капитал салуларга субсидияләр);

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 78.1 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацы нигезендә, учреждениеләргә (алга таба – максатчан субсидияләр).

2. Түбәндәге файдаланылмый калган калдыклар түләтелергә тиеш:

учреждениеләрнең гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы тарафыннан яки предприятиеләргә капитал салуларга субсидияләр бирүне хәл итүче бюджет средстволарын тиешле баш бүлүчеләр (алга таба – бюджет средстволарын баш бүлүче) тарафыннан агымдагы финанс елында шул ук максатларга субсидияләр җибәрүгә ихтыяҗның булуы турында карар кабул ителмәгәндә, капитал салуларга субсидияләр (алга таба – түләтелергә тиешле капитал салуларга субсидияләр калдыклары);

гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган тарафыннан агымдагы финанс елында шул ук максатларга субсидияләр җибәрүгә ихтыяҗның булуы турында карар кабул ителмәгәндә, максатчан субсидияләр (алга таба – түләтелергә тиешле максатчан субсидияләр калдыклар).

3. Агымдагы финанс елында шул ук максатларга максатчан субсидия калдыкларын, капитал салуларга субсидия калдыкларын җибәрүгә ихтыяҗ турында карар кабул иткән, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (баш бүлүче) хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына (алга таба – Казначылык департаменты), башка максатларга субсидияләр рәвешендә, шулай ук бюджет инвестицияләре рәвешендә Татарстан Республикасы бюджетыннан бирелә торган средстволар белән операцияләр учеты өчен учреждениегә, предприятиегә лицевой счет (алга таба – аерым лицевой счет) ачу урыны буенча Казначылык департаментының территориаль бүлегенә, бу Тәртипкә № 1 кушымта нигезендәге форма буенча, 20___ елга бюджет (автоном) учреждениеләренә бирелгән максатчан субсидияләр белән операцияләр турында мәгълүматларны, бу Тәртипкә № 2 кушымта нигезендәге форма буенча, 20___ елга бюджет (автоном) учреждениесенә, дәүләт унитар предприятиесенә бирелгән капитал салуларга субсидияләр белән операцияләр турында мәгълүматларны тапшыра.

4. Агымдагы финанс елында шул ук максатларга капитал салуларга субсидияләр калдыкларын һәм максатчан субсидияләр калдыкларын җибәрүгә ихтыяҗның булуы турында карар кабул ителмәгән очракта, гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (бюджет средстволарын баш бүлүче) хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 февраленә кадәр Казначылык департаментына, учреждениегә, предприятиегә аерым лицевой счет ачу урыны буенча Казначылык департаментының территориаль бүлегенә, бу Тәртипкә № 3 кушымта нигезендәге форма буенча, түләтелергә тиешле капитал салуларга субсидияләр калдыкларын, түләтелергә тиешле максатчан субсидияләр калдыкларын түләтү турында уведомление (алга таба – Уведомление) җибәрә.

Уведомление түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

номеры һәм датасы;

гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (бюджет средстволарын баш бүлүче) атамасы;

түләтелергә тиешле капитал салуларга субсидияләр калдыклары, түләтелергә тиешле максатчан субсидияләр калдыклары үзеннән түләтелә торган учреждение, предприятие атамасы;

субсидия атамасы;

түләтелергә тиешле капитал салуларга субсидияләр калдыкларын, түләтелергә тиешле максатчан субсидияләр калдыкларын кире кайтару буенча бюджет керемнәре чыганаклары үзенә билгеләнгән Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органының (алга таба – бюджет керемнәре администраторы) идентификация салым түләүче номеры (ИНН) һәм салым учетына кую сәбәбе коды (КПП), бюджет керемнәренең баш администраторы коды, бюджет керемнәре администраторының лицевой счеты номеры;

капитал салуларга субсидияләр, максатчан субсидияләр белән, капитал салуларга бирелгән субсидияләр, максатчан субсидияләр (субсидия коды) буенча операцияләр учеты өчен Казначылык департаменты тарафыннан бирелгән аналитик кодлар һәм аларга туры килә торган суммалар.

Уведомлениедә гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (бюджет средстволарын баш бүлүче) җитәкчесе һәм баш бухгалтеры имзасы (тулысынча күрсәтеп) булырга тиеш.

5. Хисап елыннан соң килүче финанс елының 1 февраленә кадәр гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (бюджет средстволарын баш бүлүче) бу Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән Уведомлениене Казначылык департаментына, Казначылык департаментының территориаль бүлегенә тапшырмаган очракта, Казначылык департаменты түләтелергә тиешле максатчан субсидияләр калдыкларын, түләтелергә тиешле капитал салуга субсидияләр калдыкларын түләтүне, алга таба әлеге субсидияләр калдыкларын Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерү өчен, “Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары арасында Федераль казначылык органнары тарафыннан бүленә торган керемнәр” № 40101 баланс счетында ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган счетына күчерү юлы белән хәл итә.

6. Казначылык департаменты, Казначылык департаментының территориаль бүлеге Уведомление алгач, алу турында билге куеп, уведомление алынганнан соң өч эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче органга (бюджет средстволарын баш бүлүче) алу турында билге белән уведомление күчермәсен җибәрә.

7. Түләтелергә тиешле капитал салуларга субсидияләр калдыкларын һәм түләтелергә тиешле максатчан субсидияләр калдыкларын күчерү, түләү документлары нигезендә учреждениегә, предприятиегә ачылган аерым лицевой счетта исәпкә алган средстволарның гомуми калдыгы чикләрендә, казначылык департаменты, казначылык департаментының территориаль бүлекләре тарафыннан № 40101 счетка хәл ителә.

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының _________ 2016г. № 21-53-
боерыгы
белән расланган, Лицевой счетлары
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган
Татарстан Республикасы бюджет һәм
автономияле учреждениеләргә, дәүләт унитар
предприятиеләренә
Татарстан Республикасы бюджетыннан
бирелгән субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын
түләтү тәртибенә №1 кушымта

РАСЛЫЙМ

Җитәкче _______________ _________ _______________

(вәкаләтле зат) (вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)

____________________________________________________

Учреждениенең гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (бюджет средстволарын баш бүлүче) атамасы

________________________________________________________

«__» ________________________ 20__ ел

20__ елга бюджет (автоном) учреждениесенә тапшырылган максатчан субсидияләр белән операцияләр турында
МӘГЪЛҮМАТЛАР
"__" ________________ 20__ ел

Бюджет (автоном) учреждениесе ___________________________

| | | | |
|---|---|---|---|
| ИНН | | КПП | |
| Алдагы мәгълүматларны тапшыру датасы | | | |
| Бюджет атамас___________________________ОКТМО буенча | | | |
| Гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен башкаручы орган атамасы___________________________ БК буенча бүлек | | | |
| Максатчан субсидияләр белән операцияләр учеты өчен лицевой счетны алып баручы орган атамасы ____________________________ ОКЕИ буенча | | | |

Үлчәү берәмлеге: сум.

| Субсидия атамасы | Субсидия коды | 20__ ел башына узган еллар субсидияләренең файдалануга рөхсәт ителгән калдыгы | Узган елларның дебиторлык бурычын кире кайтару суммасы | Планлаштырыла торган | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сумма | сумма | керемнәр | түләүләр |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| Барлыгы | | | | | |

| | |
|---|---|
| Бит номеры | |
| Битләр барлыгы | |

Җитәкче ____________ __________________________
(имза) (тулы имза)

Финанс-икътисад хезмәте җитәкчесе ______________ ________________________________
(имза) (тулы имза)

Җаваплы эш башкаручы ____________ ______________ ____________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)

«___» ______________20___ел

Бу Мәгълүматларны кабул итеп алу турында Казначылык департаменты, Казначылык департаментының территориаль органы билгесе

Җаваплы эш башкаручы:
__________ ____________ ____________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)
«___» ______________20___ел

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының _________ 2016г. № 21-53-боерыгы
белән расланган, Лицевой счетлары
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган
Татарстан Республикасы бюджет һәм
автономияле учреждениеләргә, дәүләт унитар
предприятиеләренә
Татарстан Республикасы бюджетыннан
бирелгән субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын
түләтү тәртибенә №2 кушымта

РАСЛЫЙМ

Җитәкче _______________ _________ _______________

(вәкаләтле зат)(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)

_____________________________________________________

Учреждениенең гамәлгә куючысы функцияләрен һәм вәкаләтләрен хәл итүче орган (бюджет средстволарын баш бүлүче) атамасы

_________________________________________________________

«__» _________________________ 20__ ел

20__ елга бюджет (автоном) учреждениесенә, дәүләт унитар предприятиесенә бирелгән капитал салуларга субсидияләр белән операцияләр турында
МӘГЪЛҮМАТЛАР

"__" ________________ 20__ ел

Бюджет (автоном) учреждениесе, дәүләт
унитар предприятиесе ___________________________

| | |
|---|---|
| ИНН ______ КПП | |
| Алдагы мәгълүматларны тапшыру датасы | |
| Бюджет атамасы____________________________ОКТМО буенча | |
| Бюджет средстволарын баш бүлүче атамасы ____________________________________________БК буенча бүлек | |
| Капитал салуларга субсидияләр белән операцияләр учеты өчен лицевой счетны алып баручы орган атамасы _______________ ОКЕИ буенча | |

Үлчәү берәмлеге: сум.

| Субсидия атамасы | Субсидия коды | 20__ ел башына узган еллар субсидияләренең файдалануга рөхсәт ителгән калдыгы | Узган елларның дебиторлык бурычын кире кайтару суммасы | Планлаштырыла торган | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | сумма | сумма | керемнәр | түләүләр |
| | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| | | | | | |
| Барлыгы | | | | | |

Бит номеры

Битләр барлыгы

Җитәкче __________ ______________________
(имза) (тулы имза)

Финанс-икътисад
хезмәте җитәкчесе ____________ ___________________________
(имза) (тулы имза)

Җаваплы
эш башкаручы __________ ____________ ________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)
«___» _______________20___ел

Бу Мәгълүматларны кабул итеп алу турында Казначылык департаменты, Казначылык департаментының территориаль органы билгесе

Җаваплы эш башкаручы:
___________ _____________ ____________
(вазыйфасы) (имзасы) (тулы имзасы)
«___» ______________20___ел

Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгының _________ 2016г. № 21-53-
боерыгы
белән расланган, Лицевой счетлары
Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган
Татарстан Республикасы бюджет һәм
автономияле учреждениеләргә, дәүләт унитар
предприятиеләренә
Татарстан Республикасы бюджетыннан
бирелгән субсидияләрнең файдаланылмый калган калдыкларын
түләтү тәртибенә №3 кушымта

УВЕДОМЛЕНИЕ N

Файдаланылмый калган капитал салуларга субсидияләр калдыкларын һәм
максатчан субсидияләр калдыкларын түләтү турында

от "__" ________ 20 г.

| | | КОДЛАР |
|---|---|---|
| | | |
| | ИНН | |
| | КПП | |
| Гамәлгә куючы функцияләрен һәм Вәкаләтләрен башкаручы орган (бюджет средстволарын баш бүлүче)______________________________ | | |
| | БК буенча бүлек | |
| Бюджет (автоном) учреждение Дәүләт унитарное предприятиесе ________________ | | |
| | лиц.счет № | |

Үлчәү берәмлеге: сум.

| Субсидия коды | 20__ елның 1 гыйнварына файдаланмый калган субсидия калдыгы | | |
|---|---|---|---|
| | гомуми сумма | кире кайтарылырга тиешле | ихтыяҗы расланган |
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| Барлыгы: | | | |

Җитәкче
(вәкаләтле зат) ____________________ ___________________________________
(имза) (тулы имза)
Баш бухгалтер
(вәкаләтле зат) ____________________ ___________________________________
(имза) (тулы имза)
"__" ________ 20__ ел

Җаваплы эш башкаручы __________(Ф.И.О.), телефоны _______